**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле кертелгән карантинны бетерү турында

Терлекләрнең котыру белән чирләвенең соңгы очрагыннан соң ике ай узуы, эпизоотиягә каршы һәм профилактик чаралар уздырылу белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законының $3^1$ статьясы нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасының түбәндәге аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле кертелгән карантинны бетерергә:

Алексеевск районының Алексеевск шәһәр тибындагы поселогында Калинин урамы;

Кукмара районының Лельвиж авылындагы Совет урамы;

Нурлат районының Яңа Иглай авылындагы Үзәк урам;

Питрәч районының Колкамәр авылындагы Мәктәп урамы;

Балык Бистәсе районының Ямаш авылындагы Һади Такташ урамы;

Кукмара районының Иске Юмья авылы янындагы «Сөт Иле» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте филиалы – «Әсәнбаш» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең (Заря бүлекчәсе) яшь терлек асрау өчен файдаланылучы территориясенең бер өлеше.

2. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында» 2015 елның 25 апрелендәге ПУ-415 номерлы Указы үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2015 ел, 01 июль
№ ПУ-610